ОНЛАЙН СӘҮДӘ

Дәүләт Советында кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм чаралары турында сөйләштеләр

> 2

АРЗАН ЯГУЛЫК

«Тимер ат»ларны газга күчермәкчеләр

> 2

ФӘНИЯ ӘХМӘТҖАНОВА:

«Геройларым белән бергә яшим»

> 3

ЫШАНЫЧ

«ВТ»ның Татарстанда яшәүче милләтләр турындагы махсус проекты

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 36 (29003) | Чәршәмбе | 15 март | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

РӘХМӘТ ҺӘМ САБЫРЛЫК АЕ

Мөселманнарның ел буе зарыгып көткән рамазан ае башланырга санаулы көннәр калып бара. 22 мартта мәчетләрдә беренче тәравих намазы укылачак. 23 март – уразаның беренче көне. Һәр мөселман рамазанны зур бәйрәм, олы бәхет буларак кабул итә. Башка еллардан аермалы буларак, быел бу айда Татарстандагы биналар да бәйрәмчә бизәләчәк. Санаулы көннәрдән башланачак рамазан ае безне тагынниләр белән сөендерер? Журналистлар белән очрашуда шул хакта сөйләделәр.

Өч көн генә аз

Адәм баласыннан бик нык рухи әзерлек, ихтыяр көче сорый торган чорга аяк басабыз. Татарстан мөфтиенең мөхтәсибәтләр эшчәнлеге буенча урынбасары Равил хәзрәт Зөфәров сүзләре белән әйтсәк, рамазан ае – рәхмәт, сабырлык, җәһәннәмдә уттан котылу, бер-беребезгә ярдәм итү, Коръәни Кәрим ае да.

– Түземсезлек белән мөбарәк ай – рамазаныбызны көтәбез. Рәсүлебез саллаллаһу гәләйһи вә сәлләмнең хәдисендә: «Кайсы Аллаһының бәндәсе Рамазан Шәрифне зарыгып көтсә, кайгырып озатса, ул җәннәттә булыр», – диелә. Бу – олы сәгадәт. Мөэмин мөселман сау-сәламәт, балигълыкка ирешкән икән, изге рамазан аенда ураза тота, Раббыбызның рәхмәтенә, нигъмәтләренә омтыла. Рамазан ае – бер-беребезгә, мохтаҗларга ярдәм кулы суза торган, Аллаһ Раббыбызның барлыгын искә төшерә торган ай. Аллаһыбыз кабуллардан кылса иде, – ди ул.

Быел рамазан ае 22 мартта кояш баеганнан соң керә. Беренче тәравих намазы шул ук көнне ястү намазыннан соң укыла. Быел ураза 29 көн тотыла. Ураза бәйрәме 21 апрельгә туры килә. Равил хәзрәт Зөфәров сүзләренә караганда, республикакүләм ифтар быел да зурлап үткәреләчәк.

– Ифтарны быел да зурлап үткәрергә җыенабыз. Ул – уразаның йөзек кашы. Үткәрү вакыты – якынча 14–15 апрель. Ул «Казан Экспо»да узачак. Анда 11 меңләп кеше катнашачак. Республикабыз шәһәрләреннән, авылларыннан булган кардәшләребезгә билетлар таратылачак. Мохтаҗ кардәшләребез дә шул чарада катнашачак, – ди хәзрәт.

Татарстан Диния нәзарәтенең Голәмәләр Шурасы һәм казыйлар Шурасы бу көннәрдә фитыр сәдакасы, фидия һәм зәкят нисабы күләмнәрен дә раслаган.

Ай дәвамында республика мәчетләрендә ифтар мәҗлесләре узачак. Казанда ул 41 мәчеттә үткәреләчәк. Аларның исемлеге белән нәзарәт сайтында (www.dumrt.ru) танышырга мөмкин. Казанның «Галиев» мәчетендә көн саен өйлә намазыннан соң Коръән укылачак. Нәзарәтнең телеграм-каналында хәтемнең турыдан-туры трансляциясе алып барылачак. Хәтем шулай ук башка кайбер мәчетләрдә дә кылыначак.

Нәзарәтнең шәригать мәсьәләләре буенча бүлек җитәкчесе – Казан шәһәре казые Булат хәзрәт Мөбарәков белдерүенчә, ураза һәр көнне тотылырга тиеш.

tatarstan.ru

– Ураза ул – һәр көн өчен ният кылып, таң атканнан алып кояш батканга кадәр ашау-эчүдән, җенси мөнәсәбәттән тыелып тору. Ният һәр көн өчен кылынырга тиеш. Кайберәүләр уразаны башында, уртасында, ахырында өчәр көн генә тотсаң да ярый, дип саный. Бу алай түгел. Ураза һәр көнне тотылырга тиеш. Бары шул вакытта гына без пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм вәгъдә иткән әҗер-савапка ирешәчәкбез, – ди ул.

Бинада да – рамазан

Башка еллардан аермалы буларак, быел рамазан аенда республикабыздагы биналар да бәйрәмчә бизәләчәк. Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин тәкъдиме белән республика оешмалары арасында «Нурлы рамазан» бәйгесе игълан ителгән. Моның өчен алар кафе, рестораннар, кибет, сәүдә үзәкләре, салон, мәчет, уку йортлары кебек халык күп йөри торган урыннарны бәйрәмчә итеп бизәргә тиешләр. Җиңүче оешмага хаҗга юллама бүләк ителәчәк. Башка җиңүчеләрне дә мактау кәгазьләре һәм истәлекле бүләкләр көтә.

Проектны оештыручыларның берсе Айгөл Биктимерова сүзләренә караганда, бу матур гадәт мөселман илләрендә күптән яшәп килә инде. Быелдан башлап аны Татарстанда да гадәткә кертмәкчеләр.

– Бу бәйгене рамазан ае килүен ураза тотучы, намаз укучы мөселманнар гына түгел, республикада яшәүче башка халыклар да: «Рамазан ае җиткән икән, рамазан уразасын тота башлаганнар икән», – дигән уй белән яшәсен, алар да бу турыда белсен, үзләре дә шушы рамазан ае кыйммәтләрен өйрәнеп, шуңа тартылсыннар, дигән ният белән башлап җибәрдек. Төп таләп – биналар ислам һәм рамазан символикасын кулланып бизәлергә тиеш. Аның тәүлек әйләнәсе күренеп торуы, Ураза бәйрәменә кадәр саклануы да мөһим, – дип сөйләде ул.

Бәйгедә катнашу өчен 2023 елның 25 мартына кадәр WhatsApp яки Telegram аша +79605438039 номерына оешманың җитәкчесен, атамасын, телефонын, төгәл адресын күрсәтеп, бизәлешнең фото яки видеосын җибәрергә кирәк.

ФИТЫР СӘДАКАСЫ, ФИДИЯ ҺӘМ ЗӘКЯТ НИСАБЫ КҮЛӘМНӘРЕ

➤Нәзарәтнең Голәмәләр Шурасы һәм Казыйлар Шурасы карары белән, фитыр сәдакасын түләү өчен нисаб күләме – 41000 сум (көмеш буенча), зәкят чыгару өчен нисаб күләме – 454000 сум (алтын буенча) билгеләнде.

➤Фитыр сәдакасы арпа буенча исәпләгәндә – 150 сум, йөзем белән исәпләгәндә – 800 сум.

➤Моннан тыш, сәламәтлеккә бәйле рәвештә ураза тоту мөмкинлегенә ия булмаган һәм аны башка вакытта да каза кылып үти алмаучылар өчен тотылмый калган һәр көн өчен 350 сум күләмендә фидия билгеләнде.

Ахыры 2 нче биттә >

Хәрбиләр ташуга әзерләнә

Быел язын Татарстанда, шулай ук Башкортстанда язгы ташу чорында су басуга бәйле киеренкелек көтелә. «Интерфакс» хәбәренә караганда, Үзәк хәрби округы җаваплылыгындагы Алтай крае һәм Чиләбе өлкәсендә дә су басу куркынычы зур. Хәрби округ белгечләре хәзер Идел буе, Урал һәм Себер елгаларының су юлларын тикшерү, бозның калынлыгын үлчәү, аны шартлату өчен кирәк булган шартлаткыч күләмен исәпләп чыгару белән мәшгуль. Алар әйтүенчә, елгаларны ясалма ачу (бозны шартлатып) боз «бөке»ләреннән котылу, күперләр, гидротехник корылмаларны саклап калу мөмкинлеге бирә. Үзәк хәрби округы быел язгы ташуга каршы көрәшү өчен 35 төркем булдырган.

Сүз уңаеннан, март ахырында Казан янындагы бистәләрдә су басулар булырга мөмкин, дип фаразлана. Апрельнең беренче яртысында Казансу һәм Идел елгалары боздан арынырга тиеш.

Бурыч белән шаярма

Ел башыннан бирле Татарстанда суд приставлары салым түләмәүчеләрнең мөлкәтенә арест салу турында 322 карар чыгарган. Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан идарәсе матбугат хезмәте хәбәренә караганда, шушы вакыт эчендә бурычлыларның 80 автомобиленә, 37 күчемсез милкенә (37 миллион сумлык) «йозак» эленгән. Салым түләмәүчеләрдән алынган барлык мөлкәтнең гомуми бәясе 99 миллион сум тәшкил иткән.

Гамәлдәге закон буенча, бурыч күләме 3 мең сумнан арткан очракта, суд приставлары мөлкәткә арест салырга мөмкин. Ә инде бурычлымы-түгелме икәнеңне белү өчен, Суд приставлары хезмәтенең рәсми сайтындагы «Банк данных исполнительных производств» сервисына кереп карарга киңәш ителә.

Ял итәргә акча бирәләр

Татарстанда дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар хезмәткәрләрен бюджет акчасы хисабына шифаханәдә ял иттерү буенча пилот проекты бер елга озайтылган. Министрлар Кабинетында бу җәһәттән тиешле карарга кул куелган.

Бу хезмәткәрләр 25 мең сумлык сертификат алырга мөмкин. Аның белән республикадагы шифаханә-курортка юллама бәясен тулысынча яки өлешчә түләргә була. Шифаханәне мөстәкыйль сайлап алу рөхсәт ителә. Тик бер шарты бар: ул Россия Курортлар фонды реестрына кертелеп, Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән килешү төзегән булырга тиеш.

Юллама өчен Татарстан бюджетыннан түләнә. Ләкин бу – исемле сертификат. Ягъни аны башка берәүгә биреп булмый, дигән сүз. Сертификат алу өчен, социаль яклау бүлегенә гариза (эш урыныннан белешмә белән бергә) тапшырырга кирәк. Аның белән 2023 елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча түләү сорала.

Сак булыгыз!

Хыянәт итмә һәм «лайк» куй!

МОШЕННИКЛАР ЯҢА АЛДАУ ЫСУЛЫ ТАПКАН

Ватаныңа хыянәт итәсең! Соңгы арада мошенниклар, үзләрен ФСБ хезмәткәрләре дип таныштырып, кешеләрне Украина армиясенә акча күчерүдә гаепле икән. Бу хакта Саклык банкы кисәтә.

Халыкны төп башына утыртуның яңа тәртибе болайрак: мошенниклар банк клиентларына шалтыратып, үзләрен ФСБ хезмәткәре дип таныштыра. Шуннан соң аларның исеменнән Украина армиясенә акча күчерелүе турында хәбәр итә. Имеш, банк хезмәткәрләре, клиентларының шәхси мәгълүматларын урлап, алар исеменнән акча күчереп ята. Алай гына да түгел, кырыгалдарлар, тиз арада ни дә булса эшләмәсәгез, җинаять җаваплылыгына тартылачаксыз, дип ышандыра. Моны булдырмас өчен, алданучыны «куркынычсызлык хезмәте»нә кушылып, карталарындагы акчаны алар счетына күчерергә мәҗбүр итәләр икән.

– Нәтиҗәдә мошенниклар корбаны аларга үз акчасын күчереп кенә калмый, ә, паникага бирелеп, кредитлар ала һәм ул акчаны да мошенникларга күчерә, – ди Саклык банкы идарәсе рәисе урынбасары Станислав Кузнецов.

Тагын бер кат искәртсәк, зыяны тимәс: банк хезмәткәрләре беркайчан да клиентларының шәхси мәгълүматларын сорап, йә булмаса, акчагызны югалтырга мөмкинсез, дип куркытып шалтыратмый; алар клиентның банк картасы номерларын, смс аша килгән парольләр дә сорамый. Игътибарлы һәм сак булыйк!

Шушы арада гына бер алдау юлы турында билгеле булды. Чаллыда яшәүче ханым шуның аркасында 180 мең сум акчасыннан колак каккан. Татарстан буенча Эчке эшләр

Илдар Мөхәммәтҗанов

министрлыгының рәсми сайтындагы мәгълүматтан күренгәнчә, башта аңа бары тик интернет-кибеттә «лайк»лар куеп, «товар сатарга» гына кушкан булалар. Имеш, «лайк» куеп, тегеяисә бу товарны хупларга кирәк. Ялган менеджерлар биремнәрен социаль челтәрләр аша сылтама рәвешендә җибәрә торган, ә бу ханым барысын да җиренә җиткереп үти барган.

Шуннан соң аңа, имештер, теге яки бу товарга ихтыяҗны арттыру өчен, товарларны юри генә сатып алырга тәкъдим иткәннәр. Товарга тотылган акчасының арттырылган күләмдә үз счетына кире кайтарылачагын әйткәннәр. Шулай итә-итә, ул 180 мең сумнан артык акчага товар сатып алган. Әмма аңа акчасын да, «эшләп тапкан» керемен дә җибәрүче булмаган. Кырыгалдарлар корбаны булганын белүгә, Чаллыда яшәүче бу ханым полиция хезмәткәрләренә мөрәҗәгать иткән.

Сүзгә-сүз

dvor.tatar

Арина ПЕТРОВА, «Безнең ишегалды» программасы кураторы:

Акчаның 83 проценты юл эшләренә тотыла. Иң күләмле эш шушы инде. Быел ишегалдындагы юлларны төзекләндерүне апрель аенда башлап, 30 августка төгәлләргә ниятлибез. Халык яшелләндерүгә дә игътибарлы. Әгәр «Безнең ишегалды» программасы буенча подрядчы оешма үсеп утырган агачка зыян сала икән, аның урынына өчне утыртырга тиеш».

(Татарстанның төбәкләр белән идарә итү үзәгендә узган туры эфирдан)

РОССИЯДӘ – ТУРИЗМ

«SuperJob» эш эзләү хезмәте Россиядә яшәүчеләрдән җәйге ялны ничек үткәрергә хыяллануларын сорашкан.

Пандемия бетә!

COVID-19 пандемиясе быел, ниһаять, тәмамланып, вирус таралу аркасында кертелгән дөньякүләм гадәттән тыш хәл режимы юкка чыгарылырга тиеш. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы генераль директоры Тедрос Аданом Гибрейесус шулай дип белдергән. Бу чынга ашса, алга таба сәламәтлек саклау өлкәсендә коронавируска бәйле хәлне эпидемия дип кенә атарга мөмкин булачак.

11 мартта ковидка 3 «яшь» тулды. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы килеп туган вазгыятьне нәкъ менә шул чакта – 3 ел элек пандемия дип бәяләгән. Хәзерге вакытта коронавируска бәйле хәлләр яхшыра. Генераль директор сүзләренә караганда, вирустан атналык үлем-китем күрсәткече күпкә түбән дәрәҗәдә теркәлә башлаган.

Гибрейесус фикеренчә, пандемия сәламәтлек саклауга, фәнни тикшеренүләр һәм халыкара хезмәттәшлеккә акча кызганмауның мөһимлеген раслаган.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БАНК ЯНГЫНЫН АКЧА СИБЕП СҮНДЕРӘЛӘР

Америкадагы банк түнтәрелеше дөнья яңалыкларының иң әһәмиятлесенә әйләнде. Банкротлыкка чыккан банклар чылбыр реакциясе биреп, дөньякүләм финанс кризисын тудырсалар, хәл кискен начараячак иде. Бер нәрсәгә игътибар итик: Америка банкларының проблемалары турында беренче хәбәрләр күренүгә үк, нефть бәясе түбәнгә китте. Финанс хакимиятләренең вазгыятьне тотрыкландырырга вәгъдәләре ишетелү белән янә югары күтәрелде. Әгәр глобаль кризис, ниһаять, башланса, нефть бәяләре белән генә котылып калып булмаячак: җитештерү мәйданнарының тукталуы, масштаблы эшсезлек, фәкыйрьлек һәм ачлык мәйданга чыгачак. Һәркем белә: моңа юл куярга ярамый. Дүшәмбе көнне ФРСның гадәттән тыш һәм ашыгыч утырышка җыелуы, Байденның милләткә мөрәҗәгать белән чыгуы эшләрнең никадәр катлаулы булуы хакында сөйли иде. Никадәр генә ашыгыч чаралар күрелмәсен, чылбыр реакциясе һәм банк афтершоклары барыбер күзәтелде. Европа Үзәк банкы Baltic International Bankның лицензиясен алды. Американың төбәк банкларының котировкалары кискен түбәнгә очты. 75 процентка кадәр бәясен югалткан банклар бар. Европаның зур банклары да очсызлана. Credit Suisse – 14, KbW – 12, Commerzbank – 11, Deutsche bank һәм Raiffaisen 7 процент кыйммәтләреннән колак кактылар. Мәсьәләгә болай карыйк: әгәр син үткән атнада Credit Suisseның акциясен алган булсаң, дүшәмбе көнгә 14 процент акчаңны югалтып өлгердең. Аңлашыла инде: саннар инвесторларда (спекулянтлар дип укы) паника уята. Алар калган акчаларын коткару өчен, банк кәгазьләреннән котылырга теләячәкләр. Ул теләк җимерелүне тагын да тизләтәчәк. Шуңа күрә дүшәмбе көнне биржалар күп кенә компанияләрнең акцияләре белән сәүдәне туктатып торырга мәҗбүр булдылар. Франциянең икътисад министры Брюно Ле Мэр инвесторларны тынычланырга чакырды.

Федераль резерв системасының утырышы мәсьәләгә ачыклык кертергә тиеш иде. Гадәттән тыш утырышка ФРС кына түгел, Бундесбанк та (немец регуляторы) җыелды. Швейцария регуляторы «вазгыятьне күз дә алмый» күзәтеп торуын белдерде. Американнар нигездә мондыйрак коткару чаралары күрделәр: янган банктагы депозитларны тулысынча түләргә (элек 250 мең долларга кадәрге керемнәр генә кайтарыла иде), хәлләре мөшкел булган банкларга акча бирергә. ФРС банкларның бәясе төшкән акцияләрен номиналь бәядән, ягъни кәгазьдә язылган сан белән сатып алачак. Бу банкларны банкротлыктан коткарырга тиеш. Банкның кертем ияләренә түләргә акчасы табылмаса, рәхим итеп ФРС акчасы белән түләячәк. Финанс министрлыгы да катнашачак, билгеле, югалтуларны каплауда. Банклар акцияләрне сатмыйлар, шуларны залог итеп, ФРСтан кредит алалар, шундый механизм каралган. Бу чаралар кертем ияләрен һәм инвесторларны тынычландырырга тиеш. Байден да үзенең чыгышында милләткә мөрәҗәгать итеп: «Америкалылар банк системасының имин булуына ышана алалар», – диде. Янгын вакытлыча сүндерелде дип уйлыйк, әмма тирән финанс катламнарында магма кайнавын дәвам итә. Кайчан вулкан булып атасын я зур тетрәүгә әйләнәсен әлегә әйтеп булмый.

Россиядә

КЕРЕМНӘРГӘ КАРАСАҢ – КИМИ, ЧЫГЫМНАРГА КАРАСАҢ – АРТА

Россия банклары әлегә корыч кебек нык торалар. Бездә банк паникасы сизелми. Үткән тәүлекләрдә хәтта доллар курсы бераз төште. Россиялеләрнең хәлен начарайту өчен, Көнбатышта нык тырышалар. Нефть бәясен түшәм астына кертү, нефть продуктларын арзанга саттыру – төп максатлары. Блумберг агентлыгы соңгы көннәрдә Һиндстанның түшәм бәяләргә кушылуы турында хәбәр таратты. Ул дөрес булса, Мәскәү өчен зур гына проблемалар тудырачак. Путинның махсус әмере бар: түшәм бәяләрне танучыларга «кара алтын» сатмаска. Һиндстан Россия нефтенең төп импортерына әйләнеп бара. Бердән, аңа сатмасаң, кемгә сатасың, икенчедән, ул кадәр чималны кая куясың? Әмма Блумберг хәбәре рәсми рәвештә расланмады әлегә. Имеш-мимеш дәрәҗәсендә генә калды. Үткән атнада Россия нефть экспортын арттырган, кереме дә өстәлгән, билгеле. Көнбатыш глобаль көч буларак үзенең йогынтысын югалтып бара дигән сүз бу. Шулай да чимал экспорты белән проблемалар бар. Россия дизеле дөнья бәяләренең өчтән бере кадәргә түбәнәйтелгән ташлама белән сатыла. Түбән бәя белән дә сатып бетереп булмый, танкерларда җыела. 4 миллион баррель тупланган инде. Тагын ай ярым тирәсе ягулык сакларга урын бар, аннан соң тагын да түбәнрәк бәядән озатырга туры килмәгәе.

Экспорт керемнәре кимү безнең матди хәлне начарайтыр. Әлегә бездә барысы да ал да гөл. Инфляция бар, әмма түзәрлек. Әнә газета хәбәрчесенә Төркиядән хәбәр итәләр: «Бәяләрнең бу тизлектә үсүен күргәнем юк иде әле», – диләр. Туксанынчы елларны күрмәгән егет яза. Бездәге туксанынчы елларны күрсә, шөкер итәр иде.

Росстат, Россиядә фәкыйрьләр саны кими, дип хәбәр итә. Исегезгә төшерәбез: кеременң яшәү минимумыннан ким булса, фәкыйрь булып саналасың. Татарстанда яшәү минимумы 13319 сум дип беләм. Росстат 15,3 миллион кешенең кереме минимумнан ким дип санаган. Бу – яңа Россия тарихында иң түбән күрсәткеч. Фәкыйрьләр саны 10,5 процентка калган. Чынлап та, 2022 елда Россия бик зур экспорт керемнәре алды шул. Шулай булгач статистикага ышанырга туры килә. Бәхәсләшергә була инде: «13 мең сум акчага ничек яшәп була?» – дип. Әмма яшиләр бит әле. Кысылып булса да, гомер сөрә халык.

Мәсьәләгә башка яктан карасаң, хәл үзгәрә. Начар ниятле кешеләр күп. Шулар россиялеләрнең керемнәрен түгел, чыгымнарын исәпләгәннәр. Азык-төлеккә, башка товарларга һәм хезмәтләргә россиялеләр тоткан акчаны санаганнар да 29,3 миллион кешенең чыгымнары фәкыйрьлек чигеннән түбән дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Бу – 20,2 процент. Чыгымнар буенча исәпләгндә, фәкыйрьләр саны ике тапкыр арта да китә. 2023 елда илнең экспорт керемнәре күпкә кимрәк булачак. Бу – бәхәссез. Яңа чынбарлыкта фәкыйрьләр саны күпмегә артыр – санамый әйтеп булмый.

Яшәргә өйрәнәбез

ТЫРЫШКАН ТАБАР

Татарстанда 800 меңнән артык кеше үз көнен үзе күреп яши. Сүз кече һәм урта бизнес вәкилләре турында бара. Былтыр төрле интернет-кибетләрдә сатучылар саны гына да ике тапкыр диярлек арткан әнә. Эшкуарларга ярдәм чаралары турында Татарстан Дәүләт Советында сөйләштеләр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Парламентта Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты утырышы узды. Анда Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов та катнашты. Татарстан Рәисе каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Фәрит Абдулганиев сүзләренә караганда, республикадагы барлык эш урыннарының 42 проценты кече һәм урта бизнес тармагына туры килә.

– Бу – республиканың социаль-икътисадый үсешен билгеләүче зур армия, – диде ул. – Сер түгел, соңгы өч елда эшмәкәрләргә шактый сынау узарга туры килде. Шуңа да карамастан, без бер урында гына туктап тормыйбыз. Бүген Татарстанда 168 меңнән артык кече һәм урта бизнес субъекты исәпләнә. Алдагы елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, күрсәткеч 2,4 процентка үскән.

Вәкаләтле вәкил әйтүенчә, тармакта тотрыклылыкны сакларга дәүләттән күрсәтелүче ярдәм чаралары булыша. Хәер, эшкуарлар үзләре дә шомарып беткән инде.

– Хәзер эшмәкәрләр, җитәкче ишеген шакып, үзләрен кызыксындырган сорауны бирергә курыкмый. Элек вәкаләтле вәкил аппаратында халыкны атнага бер генә көн кабул итсәк, хәзер көн саен аларның сорауларына җавап бирәбез. Телефонны төнлә дә сүндереп торган юк. Алдагы ел белән чагыштырганда, былтыр мөрәҗәгатьләр саны 10 процентка кимеде. Димәк, ике арада аңлашу бар, – диде Фәрит Абдулганиев.

Бизнес вәкилләренең «авырткан җир»ен дә әйтте ул. Эшмәкәрләр күбрәк дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының эшеннән зарлана икән. Былтыр барлык мөрәҗәгатьләрнең 26 проценты нәкъ менә шуңа туры килгән. Икенче урында – гамәлдәге законнарны аңлатып бирүгә бәйле сораулар (24 процент). Беренче өчлеккә дәүләттән ярдәм чараларына кагылышлы мөрәҗәгатьләр дә эләккән (10 процент).

– Барлык мөрәҗәгатьләрнең 70 проценты урында ук хәл ителә, – дип ышандырды вәкаләтле вәкил.

Татарстанда гына түгел, ил күләмендә эшмәкәрләрнең төн йокысын качырган бетмәс-төкәнмәс тикшерүләргә дә аерым тукталдылар. Республикада административ басым ясауны киметү юнәлешендә шактый эш башкарыла, дип тынычландырды Фәрит Абдулганиев. Фикерен саннар белән дә дәлилләде. Былтыр Татарстан бизнес үсешенә бәйле киртәләрне киметү күрсәткече буенча ил төбәкләре арасында дүртенче урынга чыккан әнә.

Республикада электрон сәүдәгә дә зур өметләр баглыйлар. Былтыр Татарстанда төрле маркетплейсларда сатучылар саны ике тапкыр диярлек арткан. Ел дәвамында алар онлайн сәүдә мәйданнары аша 50 миллиард сумлык товар саткан. Алга таба интернет-кибетләргә «йөрүчеләр» тагын да күбәеп китмәгәе. Билгеле булганча, апрельдә Татарстанда ил күләмендә тәүге «бонд склады», ягъни аерым бер таможняга беркетелгән склад ачылырга тиеш. Аның ничек эшләячәген гап-гади чит ил телевизоры мисалында карыйк. Фәлән илдәге җитештерүче бонд складына телевизорларны күмәртәләп җибәрә дә, алар чикне узмаган товар буларак (димәк, пошлина түләнми) шунда бушка сакланачак. Интернет-кибетләрдәге сатучылар исә безгә әнә шул телевизорларны алырга тәкъдим итәчәк. Ә алучысы табылгач, товарны, тиешле салымнарны түләп, складтан төяп озатасы гына кала. Телевизорның атналар буе чит илдән кайтып җиткәнен көтәсе дә юк. Сатып алучыга – товар, сатучыга – акча. Бетте китте! Бонд складлары чит илдән товар кайтартуга бәйле чыгымнарны киметәчәк, дип фаразлана. Сатылмаган товарны артык чыгымнарсыз кире озатырга да мөмкин булачак, ди.

Комитет утырышында кече һәм урта бизнеска кагылышлы гамәлдәге кануннарга үзгәрешләр кертү мәсьәләләре дә карап тикшерелде.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Рәхмәт һәм сабырлык ае

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Ярдәмләшер чак

Рамазан аенда һәр мөселман хата-кимчелекләреннән арынып, күбрәк савап эшләп калырга, мохтаҗларга ярдәм итәргә тырыша. Бу максаттан республикада ел саен «Рамазан – изге гамәлләр ае» хәйрия марафоны уздырыла. «Зәкят» фонды җитәкчесе Булат Мәрданов сүзләренә караганда, бу матур гадәт быел да дәвам итәчәк.

– Бу акция кысасында фонд берничә юнәлештә эш алып барачак. Иң беренче чиратта без 20 авыру баланың дәвалануы өчен акча күчерергә ниятлибез. Моннан тыш олы яшьтәге 20 мохтаҗ кешегә дә акчалата ярдәм күрсәтергә планлаштырабыз. Авыру, ярдәмгә мохтаҗ кешеләр безгә даими мөрәҗәгать итеп тора. Безнең фонд 1998 елдан бирле эшли. Үзебезнең базабыз бар. Анда республикабызда яшәүче 1 меңгә якын гаилә исәпләнә. Бу исемлек һәрдаим үзгәреп тора. Кемнеңдер хәле яхшыра, яңалары өстәлә, – дип сөйләде ул.

«Зәкят» фонды көн саен диярлек республикабызның төрле мәчет-мәдрәсәләрендә мохтаҗ кешеләр өчен хәйрия ашлары, ифтарлар оештырачак. Елдагыча республикакүләм ифтарга да үз өлешләрен кертмәкчеләр.

– Без мохтаҗ гаиләләргә азык-төлек белән дә ярдәм итәбез. Быел да шундый 500 гаиләгә 3,5 тонна азык-төлек таратырбыз дип торабыз. Моннан тыш һәрдаим зәкят һәм сәдака җыю белән шөгыльләнәбез. Узган рамазанда гына да мохтаҗларга 1,5 миллион сумлык фидия һәм фитыр сәдакасы тараттык, – ди Булат Мәрданов.

Теләк кенә булсын

Рамазан аенда мөселманнарны тагын ике бәйгедә катнашырга чакыралар. Шуларның берсе – ачык телевизион «Вәгазь» бәйгесе. Татар телендә оста вәгазь сөйләүчеләрне ачыклау һәм халыкка танытуны максат иткән әлеге бәйгедә 15 яше тулган һәркем катнаша ала. Алар 7 минуттан артмаган вәгазьне татар телендә яттан сөйләргә тиеш. Бәйге турында тулырак мәгълүматны Татарстан дәүләт телерадиокомпаниясе (www.trt-tv.ru) сайтында табарга мөмкин.

Татарстанда елдагыча иң яхшы азан әйтүче дә ачыкланачак. «Рухи моң» татар рухи мәдәниятне үстерү фестиваль-бәйгесендә теләге булган һәркем катнаша ала. Бәйге «Дини җыр», «Мөнәҗәт», «Милли мәкам белән азан әйтү», «Вәгазь сөйләү» номинацияләрендә үткәрелә. Бәйгенең финалы 21 апрельдә – Ураза гаете көнне – башкаланың «Чулпан» мәдәният үзәгендә гала-концерт рәвешендә узачак. Бәйге турында тулырак мәгълүматны azan.tatar сайтында һәм 89274132038; 89274433404 номерлары буенча белергә мөмкин.

ГАЗ БЕЛӘН ТҮЛИСЕ АЗ

Газ ягулыгыннан курыкмаска! Машина йөртүчеләргә мөрәҗәгать бу. Экономиясе – үзегезгә, файдасы – экологиягә, диләр. Хөкүмәт йортында журналистлар белән очрашуда техниканы газ-мотор ягулыгына күчерү юнәлешендә башкарылган һәм башкарылачак эшләр турында сөйләделәр.

Татарстанның сәнәгать һәм сәүдә министры Олег Коробченко китергән мәгълүматларга тукталыйк. Бу урында сан теленә күчәрбез.

Татарстанда газ-мотор ягулыгын үстерү программасы 2013 елдан бирле гамәлдә. Министр сүзләренә караганда, 10 ел эчендә бу төр ягулыкка күчкән транспорт саны 26 тапкыр арткан. Хәзер андыйлар – 13,1 мең берәмлек.

Моның белән автомобильләргә газ тутыру станцияләре (АГНКС) саны да ишәйгән – 4,5 тапкыр артып, 44 берәмлеккә җиткән. Кысылган табигый газ куллану 16 тапкыр арткан. Аз да түгел, күп тә түгел – 72,2 млн куб метр ягулык файдаланылган.

«Бу саннар Татарстанга нәрсә бирә соң?» – дисәгез, җавабын министр сүзләреннән табарсыз:

– Болар – эшебезнең җитди күрсәткечләре. Хәзер Татарстан илдә газ-мотор ягулыгын үстерү буенча алдынгы урыннарны били, – диде Олег Коробченко.

Министр әйтүенчә, республикада газ-мотор ягулыгында эшли торган авыл хуҗалыгы тармагы, юл һәм башка төр махсус техника үрнәкләре дә бар. Быел кырларны әнә шундый тракторлар белән эшкәртә башларлар әле, шәт. Һәрхәлдә, Олег Коробченко шуңа өметләнә. Әмма икътисадый нәтиҗәләр турында әйтергә ашыкмый министр. Көтмәскә, дип тә кисәтә. Ник дигәндә, ул техниканы карап, тәэмин итеп тора торган инфраструктура әзер түгел.

Узган 10 еллык белән генә мактанып утырып булмый, билгеле. Республика киләсе 10 еллыкка программа билгеләгән инде. 2023 елда нәрсә эшләргә ниятләүләрен дә сөйләделәр.

Министр аңлатканча, быел автомобильләргә газ тутыру өчен, булган 7сенә өстәп, тагын 6 станция төзи башларга исәп. Барлыгы 13 криоАЗС булачак. Тагын бер максат – 85 млн куб метр ягулыкны куллану, 2 меңләп транспорт чарасын газ ягулыгына күчерү.

«Тимер ат»ына газ «ашатырга» җыенып йөрүчеләргә киңәшләр дә яңгырады брифингта. Иң элек моның куркынычсызрак икәнен әйттеләр. Кеше табигатькә зыян китермәү ягыннан да, акчаны янга калдыру ягыннан да ота.

«Шанс компанияләр төркеме» җәмгыяте башкарма директоры Эдуард Куприянов искәрткәнчә, машинаны бензиннан газга үзгәртеп җиһазлауга тотылган акчаның яртысын кайтару да күздә тотылган. Калган чыгымнарны ягулыклата бирәләр. Моның өчен «Газпром газ-мотор ягулыгы» махсус ягулык картасы бирә. Мисал итеп китерелгән «Лада Веста» машинасын газга көйләү якынча 100 мең сумга төшәчәк. Йөк машиналарына чыгым күбрәк: 300–500 мең сум акча тотылырга мөмкин.

Тагын бер мөмкинлек бар. Бу очракта машина хуҗасы җиһазлау өчен бөтенләй акча сарыф итми. «Машинаны газга күчерү турында гариза биреп, тиешле килешүләр төзү дә җитә. Җиһазны үзгәртү бушлай башкарылачак. Машина хуҗасы 5 ел дәвамында газ ягулыгын салачак һәм шул рәвешле җиһазлау бурычын каплаячак. Шул ук вакытта үзгәртеп кору өчен аңа бернәрсә дә түләргә кирәкми», – дип аңлатты Эдуард Куприянов.

Бу мөмкинлектән юридик затлар да файдалана ала. Алар машина өслеген реклама максатында файдалану өчен бирергә тиеш. Шулай ук җиһазлау өчен акча таләп ителми.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

АТАРГАМЫ, АТМАСКАМЫ?

Утырыштан соң

Агач череп ятмасын, төлке котырмасын, кабан дуңгызлары артмасын, тычканнар кимесен. Татарстандагы хайваннар дөньясын саклау турында Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында сөйләштеләр. Татарстанның Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе Федор Батков әйтүенчә, бүген кыргый хайваннарны исәпкә алу бара.

pixabay.com

– Безне кыргый хайваннарны бәрдерү очраклары борчуга сала. Әйтик, узган ел республикада шундый 158 очрак теркәлгән. Аларның 68ендә йөртүче авария урыныннан качкан. Билгеле инде, җавап тотасылары килми, – ди комитет рәисе. – Кызганыч, олы юл буенда күп кенә урыннарда кыргый җәнлекләр чыкмасын өчен махсус киртәләр куелмаган. Кайбер урыннарда булганы да сүтелгән. Белгечләр хайваннар тапталу куркынычы булган урыннарга 161 кисәтү билгесе дә куеп чыкты.

Федор Батков сүзләренә караганда, кыргый хайваннар саклауга мохтаҗ. Төрле авырулар аркасында аларга болай да юкка чыгу куркынычы яный. Узган ел котыру чирен булдырмас өчен, төлкеләр йөргән урыннарга 1 миллионнан артык вакцина таратканнар. Африка чумасын кисәтү максатыннан үткәрелгән чаралар нәтиҗәсендә кабаннар саны кимегән. Федор Батков аларның быел кышкы чорда исәпкә алынган санын да әйтте. Республикада 800 баш кабан дуңгызы бар. Күптән түгел үрчетелә башлаган болан һәм мараллар саны да арта.

– Без әлеге хайваннарны үрчетүне Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов тәкъдиме һәм ярдәме белән башлап җибәргән идек. Аларның саны тагын да артса, аучылар өчен квота бирә башлаячакбыз, – ди Федор Батков.

Ау дигәннән, әлегә аңа рөхсәтне кулдан язып бирәләр. Елына 8 мең кеше ауга рөхсәт сорап гариза җибәрә икән. Аның 1 меңен дөрес тутырмаган өчен кире боралар. Федор Батков, тиздән бу эшне онлайн форматка күчерәчәкбез, ди. Быел ау сезоны башланганчы 10 көн алдан рөхсәт бирелә башлаячак.

Утырышта катнашучылар кыргый этләр турында сораштылар. Чөнки кайбер районнарда аучы таныклыгы булган кешеләр хуҗалы этләрне дә аталар икән. Мондый очракта нишләргә соң? Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе Азат Хамаев сүзләренчә, этләр темасы – катлаулы мәсьәлә.

– Элек бу проблеманы хәл итү җиңел иде. Хәзер исә катлаулырак. Тагын яз җитте. Бу чорда этләр кешегә ташлана башлый. Хуҗалы этләргә тимичә, кыргый этләрне ауларга ярый, – ди ул.

Утырышта Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе урынбасары Таһир Һадиев исә «Урман кодексы»на үзгәреш кертергә тәкъдим итте. Урманнарда агачлар череп ята. Аны кешеләргә файдалану өчен бирергә кирәк, – диде ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КАЛӘМ ОСТАСЫ

Безнекеләр

Хезмәттәшебез Фәния Әхмәтҗанованың, кызып-кызып, тарих төпкеленә чумган чагы. Ниләр генә актарып чыгармый ул! Әле татар хатын-кызлары язмышын күтәрә, әле Татар цирк төркемен оештырган кешене эзләп таба, Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез белән очрашырга да вакыт таба, Россия каһарманнары батырлыклары турында да чын күңелдән, яратып яза. Элек югалган Казан алтыны табылыр дип өметләндерә. Ә үзенең күңел төпкелендә ниләр ята икән? Шушы көннәрдә 65 яшьлек юбилеен билгеләп үтәргә җыенган Фәния Кәбир кызы Әхмәтҗанова белән шул җәһәттән иркенләп сөйләшеп алдык.

Беренче карашка үзе дә тарих сыман бик җитди күренә ул. Еллар буе иңне иңгә куеп эшләсәк тә, безнең өчен ачылмаган бер зур сер кебек. Юкка-барга катышып йөрми, сүзнең чамасын белә, төпле-леген югалтмый. Хәер, язмалардан да журналистның кем икәнен чамаларга була анысы. Фәния апаның тагын бер юбилеен бәйрәм итәргә була икән әле. «Ватаным Татарстан» газетасында эшли башлавына – 20 ел. Шушы вакыт эчендә мактау сүзләрен дә, «сезне эштән куарга кирәк» дигән сүзләрне дә ишетергә туры килгән аңа. Шулай инде, журналистикада бар кешегә дә ярап бетеп булмый.

Тарих һәм татарлар

– Мин иҗат юлымны «Өмет» газетасында мөхәррир булып башлаган идем. «Ватаным Татарстан» газетасына баш мөхәррир урынбасары булып килдем. Дөресен әйтим, мондый вазыйфалар иркенләп язарга вакытны бик калдырмый. Рәхәтләнеп бер язарга иде ул, дип хыялланган чакларым да күп булды. Менә әле соңгы елларда гына баш мөхәррир тәкъдиме белән тарих темасына алындым. Бик кирәкле һәм кызыклы булып чыкты ул минем өчен. Тарихны бик аз белгәнмен икән, шуңа укыган саен, әңгәмәләр корган саен бик гаҗәпләнәм, – ди Фәния Әхмәтҗанова.

Тарихчылар белән аралашып яши ул хәзер. Араларында татар телен яхшы белгән белгечләрнең аз булуына борчыла. Шушы урында галим Фаяз Хуҗинны, ике телне дә белә, аның китаплары гади халык өчен язылган дип, башкаларга үрнәк итеп куя.

Сүз уңаеннан шунысын да әйтик: Фәния апа туган җире – Яшел Үзән районының Айдар авылы турында «Кем син, Айдар бабам?» дип исемләнгән саллы китап язып, аны авылдашларына тәкъдим итте. Бу – аның икенче китабы инде.

Хезмәттәшебез чит төбәкләрдә яшәүче татарлар турында да язуын дәвам итә. Әле күптән түгел Казахстаннан килгән милләттәшләребез белән таныштырды, Костромада яшәүче татарлар белән дә очрашып кайткан. Тарихчы галим Дамир Исхаков алар турында, томан артына кереп барган татарларның бер төркеме, дигән фикер әйтсә дә, хезмәттәшебез бу сүзләр белән килешеп бетми. «Татарстаннан читтә яшәүче татарлар үз телләрен, гореф-гадәтләрен саклау һәм яклау өчен бик тырышалар. Безнең белән чагыштыра торган да түгел», – ди.

Сүзебез татарлар темасына юнәлеш алгач, туган тел темасы да калкып чыкты.

– Кайбер саф татар авылларында балалар хәзер урамда да русча сөйләшә. Моңа каршы ничек көрәшеп була? – дигән сорауга ул болай җавап бирде:

– Минемчә, татар теленнән ваз кичә башлау иң беренче чиратта БДИга, сынауларны рус телендә бирә башлауга бәйле булды. Имтиханнарны татар телендә калдыру өчен көрәшергә кирәк иде безгә. Кайберәүләр әйтүенчә, әти-әниләрне генә гаепләү дөрес түгел, бу сәясәткә бәйле. Өйдә татарча аралашсалар да, мәктәптә балалар русча сөйләшү ягын карый. Телефон да ярдәм итә. Кызык бит: элек шәһәр балалары авылга кайтып татарча сөйләшергә өйрәнеп китә иде, хәзер киресенчә: авыл баласы рус теленә күчә. Шулай да, тел бөтенләй онытылмасын өчен, бүген бөтен өмет – әти-әниләрдә һәм укытучыларда.

Көчле математик чыгар иде

Арча педучилищесының элеккеге директоры Илдус абый Сәгъдиев белән сөйләшкән чакта: «Сездәге Фәния Сафинаны математик итеп күрәсем килгән иде. Әллә кайчан галимә булыр иде ул», – дип әйтеп куйгалый. Фәния апа әйтүенчә, журналист өчен фикер эзлеклелеге бик кирәк, математиканы яхшы белгән журналистның язмалары таркау булмый.

– Илдус абыйның, чыннан да, мине математик итәсе килгән иде. Аерым әзерләде, биремнәр дә тәкъдим итте. Шушы хәлләрдән соң, күзләренә карап, журналистикага керергә теләвем турында әйтергә дә оялып йөрдем хәтта. Бу адымым өчен очрашкан саен әрләде ул мине. Бервакыт шулай редакциягә килеп чыкты. «Ярар инде, урының да яхшы икән, язмаларың да әйбәт, мин сине гафу итәм», – диде. Шулай итеп, шактый еллар үткәч кенә мин укытучымның фатихасын ала алдым.

Тәмләп язу ничек була?

Бүген журналистика тизлек, җәһәтлек ярата. Тәмләп язарга вакыты каламы?

– Тәмләп язу – геройларың белән бергә яшәү дигән сүз инде ул. Аларның тормышын, проблемаларын үзеңнеке кебек кабул итсәң, йокың да килми, иртә таңнан торып та язарга мөмкинсең. Вакыт белән дә хисаплашмыйсың, – ди әңгәмәдәшем.

«Укучы сүзе» сәхифәсен алып баручы буларак, авторларның хатларына аеруча игътибарлы Фәния апа. «Мин беренче чиратта хат язучыны күз алдына китерәм. Ул бит журналист түгел, гади кеше. Без теләгәнчә яза алмаган икән, аның гаебе юк. Бары тик үз фикерен әйтергә теләгән. Безгә ышанган икән, димәк, өч җөмлә белән булса да, без аның теләген искә алырга тиешбез», – ди Фәния апа.

Бүген матбугатның көче аз, дигән сүзләрне дә ишетергә туры килә...

– Элек матбугатның көче, чыннан да, зуррак иде, чөнки җитәкчеләр өчен матбугатта тәнкыйть сүзе басылу ул аны төзәтергә кирәк дигән сүз булды. Үзләре битараф калса, югарыдагы җитәкчеләр аны барыбер хәл итәргә мәҗбүр итте. Кызганыч, мондый контроль бетте һәм матбугат шуңа күрә көчсезрәк булып санала. Безгә бәйле нәрсә түгел бу. Журналистлар элеккечә проблемаларны хәл итү ягында бит. Халык юкка гына моң-зарын матбугатка җиткерми. Контрольдә тотылса, тәнкыйть утына эләккән күренешләр барысы да хәл ителер иде. Ә болай һич кенә дә матбугатның көче бетте дип санамыйм. Җитәкчеләр арасында бүген дә гадел кешеләр күп, ярдәм итәләр , – ди Фәния апа.

Ә бит журналистның да күңеле кырыкка төрләнгән, кулына каләм тотасы килмәгән чаклары булгалый. Кәеф булмаса, рухи көчне, илһамны кайдан алырга?

– Көндәлек газета булгач, туктамаска, гел язып торырга кирәк. Кирәк дигән әйбер миңа кечкенәдән салынган, эленке-салынкы йөри алмыйм. Вакытында дөрес һәм төгәл итеп эшләсәм, канәгатьләнү хисе алам. Кәеф булмаса, нишлисең дисеңме? Компьютер каршына утырам да, геройларым тормышын күз алдыннан үткәрә-үткәрә яза башлыйм, алар дөньясына «күчәм». Бөтен күңелсезлекләр онытыла, кәеф тә күтәрелә.

Сәрия МИФТАХОВА

Анна Арахамия

Өйдән качкан өчен... җәза

Җир асты һәм тимер юл транспортыннан файдалану кагыйдәләрен бозганнар өчен – штрафлар, хокук бозучы үсмерләр өчен – махсус үзәкләр. Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты утырышында әнә шул мәсьәләләр хакында сөйләштеләр.

Республикада җир асты һәм тимер юл транспортыннан файдалану кагыйдәләрен бозган өчен штрафлар кертелергә мөмкин. Дәүләт Советында административ җаваплылык турында Татарстан кодексына үзгәрешләр кертергә тәкъдим иттеләр. Штрафлар ярты миллион сумга җитәргә мөмкин.

Татарстан Дәүләт техник күзәтчелеге идарәсе башлыгы Альберт Борһанов белдергәнчә, мондый хокук бозулар кешеләр сәламәтлеге өчен җитди куркыныч тудырырга мөмкин. Борһанов сүзләренчә, эксплуатацияләүгә таләпләр булуга карамастан, аларны үтәмәгән өчен җаваплылык билгеләнмәгән. Хокук бозу очраклары булганда ведомство бары тик кисәтү генә чыгара ала. Шулай итеп, мондый төр транспортлардан файдалану кагыйдәләрен бозган өчен вазыйфаи затларга яки хосусый эшмәкәрләргә 5–10 мең сум штраф яный. Юридик затларга – 20–30 мең сум. Кагыйдәләрне кабат бозган өчен вазыйфаи затларга – 40 меңнән 50 мең сумга кадәр, юридик затларга 200 меңнән 500 мең сумга кадәр штраф билгеләнергә мөмкин.

Очрашуда балалар иминлеге турында да сөйләштеләр. Депутатлар китергән статистикага караганда, ел саен федераль эзләүдә 40 меңгә якын бала тора. Узган елда өйдән чыгып киткән 569 бала җинаятьләрдә катнашкан, шуларның 99ы – җинаять корбаны, 10ысы үтерелгән. Башка сәбәпләр аркасында тагын 73 бала вафат булган. Утырышта хокук бозучы үсмерләрне махсус үзәкләргә җибәрү өчен нигезләр исемлеген киңәйтергә тәкъдим иттеләр. Элек мондый үзәкләргә ябык типтагы махсус укыту-тәрбия учреждениеләреннән качкан яки аларга суд карары буенча эләккән яшүсмерләрне генә җибәрәләр иде. Татарстанда бердәнбер шундый үзәк Казанның Яңа Савин районында урнашкан. Закондагы үзгәрешләр нидән гыйбарәт соң? Вакытлыча тоту үзәкләренә депутатлар соңгы ярты елда күп тапкыр административ җинаять кылган, шул исәптән митингларда катнашкан, экстремизмны яклаган балаларны җибәрергә кирәк дип саный. Бу исемлеккә сугышуларда, наркотикларның законсыз әйләнешендә катнашкан, транспорт чараларында милеккә зыян китергән, вак урлау кылган яки хулиганлык статьясы буенча тотылган яшүсмерләр дә керә. Алай гына да түгел: ел дәвамында өйдән яки приюттан ике тапкырдан артык качкан үсмерләрне дә шундый үзәкләргә җибәрмәкчеләр. Федераль законга үзгәрешләр Татарстан Дәүләт Советы депутатлары һәм Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов тарафыннан әзерләнгән.

Депутатлар балаларны махсус үзәкләргә урнаштыру үсмерләрнең тормышын һәм сәламәтлеген сакларга, аларның өйдән чыгып качу һәм укуларын калдыру сәбәпләрен билгеләргә мөмкинлек бирәчәк дип саный.

Ләйсән САФИНА

Мәктәп тормышы

БУ ЙОРТ СЕРЛЕ САНДЫК КЕБЕК

Сүзебез – Яшел Үзән шәһәрендә урнашкан рус телле 3 нче гимназия хакында. Монда «Телне саклыйк!» дип аталган үзәк кысасында «Серле сандык» дигән оешма эшләп килә. Ул милләтләр язмышына кагыла. Гимназиядә укучы бер меңнән артык бала арасында 11 милләт вәкиле бар. Телләрен, гореф-гадәтләрен онытмаска әнә шул серле сандык ярдәмгә килә дә инде.

Күренекле татарлар

Гимназия рус телле булса да (аның директоры Марина Ильина үзе дә рус милләтеннән), күп чаралар татар телендә оештырыла. Шушы көннәрдә генә монда сигезенче тапкыр «Үз халкын данга күмгән татарлар» дип аталган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция үткәрелде. Ул гына да түгел, монда 2010 елдан бирле «Күренекле татарлар» дип аталган музей эшләп килә. Шуның нәтиҗәседер инде, укучыларның яртысы туган тел итеп татар телен сайлый. Андыйлар арасында рус милләтеннән булган балалар да бар.

Зур эшләрнең башы шушы музейга килеп тоташа. Яшел Үзән районы, Зөя яклары талантларга бик бай. Көннәрдән бер көнне гимназиядә бу якның тарихы, шәхесләре тиешенчә өйрәнелмәгән дигән фикергә киләләр дә «Шушы җирдән, шушы туфрактан без...» дигән программа төзиләр. Яңа оешкан музей бүлмәсендә кызыклы очрашулар оештыра башлыйлар. «Башка милләт балалары да дәррәү кубып эшкә тотынды», – ди милли укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Ләйсән Хәмитова, ул чакларны искә алып. Вакыт узу белән, бу эшләр гимназия кысасына гына сыймый башлый. Башкаларны да тартырга кирәк дигән фикергә киләләр. «Аралашу» клубы ярдәмгә килә. Төрле елларда монда кемнәр генә булмаган. Мәсәлән, алар шушы гимназияне тәмамлаган композитор Рәшит Кәлимуллинның әнисе Клара апаны чакыралар. Язучы Туфан Миңнуллин да еш кунак булган монда. Якташлары Фаил Шәфигуллинның хәләл җефете Эльмира Шәрифуллина да еш килә. Вафаты алдыннан гына җырчы Усман Әлмиев белән дә күрешкәннәр. Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, Мәсгут Имашев та үз иткән музейны. Ахыр чиктә шушындый очрашулар фәнни-гамәли конференциягә нигез сала да инде. Башта анда район укучылары катнаша, аннан, республика чикләрен узып китеп, Россия күләменә тарала.

Фәнни эшләр

Конференция Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан федераль университеты, Бөтендөнья татар конгрессы белән берлектә үткәрелә. Жюри әгъзалары булып та нәкъ шушы оешмалардан, уку йортларыннан белгечләр килә. Конференциягә дип әзерләнгән эшләр музейга тапшырыла, шулай итеп, күренекле татарлар турында мәгълүматлар ел саен арта бара. Бу җәһәттән «Муса Җәлил биографиясендә билгеле булмаган фактлар», «Тукайның әкияти дөньясы», «Күренекле музейлар», «Минем шәҗәрәм» проектлары бигрәк тә зур әһәмияткә ия.

Гимназия ел саен яңа проектлар әзерли. Татарстан халыклары ассамблеясының яшьләр төркеме белән элемтәгә керүләре дә күп нәрсә биргән. Марина Ильина бу дуслыкны чын могҗизага тиңли. Кунакка да еш чакыралар икән үзләрен. Бергәләп дуслык картинасы иҗат иткәннәр, грузин кухнясы буенча мастер-класста тәмле ашлар пешерергә өйрәнгәннәр, төрле милләт халыкларының курчакларын ясаганнар. Гимназиядә бер традиция дә керткәннәр: Туган телләр көнендә 11 сыйныфтан кем бу оешмада иң активы, кичә шул укучының милләтенә багышлана икән. Шулай итеп Грузия, Әрмәнстан, Азәрбайҗан көннәрен оештырганнар да инде. Быел мәктәпне иң актив егетләрнең берсе Дамир Гилялдинов тәмамлый. Шуңа да кичә татар теленә багышланган. Ә кич белән залга әти-әниләр җыелган. Рәхәтләнеп концерт, спектакль караганнар. «Бу чарага балалар бик дулкынланып, бигрәк тә каникулда әби-бабайлары янында яшәгәндә әзерләнәләр», – ди мәктәп директоры.

Әлбәттә инде, мондый зур эшләрне яктыртып барырга да кирәк. Бу өлкәдә бернинди проблема да юк. Мәктәп телевидениесе эшләп тора. Анда көн саен истәлекле даталарга, республика, район, мәктәп тормышына багышланган тапшырулар пәйда була. «Альма матер» газетасы да калышмый. Аның кәгазь һәм электрон версиясе дә бар.

Һәр чараны яктырткан фотогалереялар да күп нәрсә турында сөйли.

Шулай итеп, серле сандык тулылана бара. Киләчәк буын өчен бик тә кирәк булыр әле ул.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Сан

Быел «Үз халкын данга күмгән татарлар» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясенең икенче турына 155 фәнни эш сайлап алынган. 255 эш онлайн каралган. Пенза, Пермь, Ульяновск өлкәләрендә, Чувашия, Удмуртия, Мордовия республикаларында яшәүче укучылар катнашкан.

Башлыйбыз яңабаштан

2014 елда Татарстан Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты «Татар әдәбияты тарихы»ның сигез томлык басмасын тәкъдим итте. Ул чакта эш 1500 данә тираж белән басылган була һәм республика китапханәләренә, мәктәп-гимназияләргә, югары уку йортларына таратыла. Киң җәмәгатьчелек сорагач, аның икенче басмасы әзерләнә башлый.

«Татар әдәбияты тарихы»ның икенче басмасы ике томлык китап рәвешендә дөнья күргән. Бу китапларны «Татар-информ»да узган матбугат очрашуында тәкъдим иттеләр һәм академик басмага кертелгән үзгәрешләр турында сөйләделәр.

– «Татар әдәбияты тарихы»ның ике басмасы да – татар гуманитар фәннәренең дәрәҗәсен күрсәтә торган кыйммәтле басмалар. Алар татарларның олуг әдәбиятын дөньяга караш, рух, рухи ныклык, характер бөтенлеге аша ачалар. Үзгәрешләр бары тик методология өлешенә генә карый, – диде Татарстан Фәннәр академиясенең вице-президенты Дания Заһидуллина.

Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин сүзләренә караганда, яңа басмаларга үзгәрешләр кертелү, шул рәвешле аларның камилләшүе – табигый күренеш. Әмма шуны аңларга кирәк: икенче басма 2014 елгы басмаларны кире какмый. Беренче һәм икенче томнарның яңа басмасында үзгәрешләр 15–20 процентны тәшкил итә. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият бүлеге мөдире Әлфәт Закирҗанов исә бу үзгәрешләргә аерым тукталды.

– Беренче басмада урын алган төп үзгәрешләр совет чоры идеологиясеннән котылу, миллилеккә борылуга бәйле. Шулар аркасында милли төсмерләр публицистика белән баетып бирелгән һәм, нәтиҗә буларак, татар әдәбияты тарихы белән гомумтөрки халыкларның тарихы арасындагы бәйлелек кимегән. Икенче үзгәреш татар әдәбиятының башлангычы булган фольклор һәм мифологиягә таянуга бәйле. Икенче басма, һичшиксез, сыйфат ягыннан баерак һәм тулырак, – диде ул.

Сүз уңаеннан, «Татар әдәбияты тарихы»ның беренче томы борынгы чорлардан XV гасырга кадәр вакыт аралыгына багышланса, икенчесе XV–XVI гасырлардан алып XVIII гасыр ахырын колачлый. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре Гамирҗан Дәүләтшин сүзләренә караганда, урта гасырларда татар халкының яшәеше Европаныкыннан күпкә аерыла. Нәтиҗәдә, европа әдәбияты белән татар әдәбияты да хронологик һәм эчтәлек ягыннан аерылалар.

– Әмма нигәдер чит җирдә туган шаблоннарга татар әдәбиятын, татар хасиятен «шыплап тутырырга» тырышканнар. Ә бит татар хасияте беренче урында булырга тиеш. Икенче басмада без шуңа омтылдык. Әмма бу – әле эшнең башы гына, – диде ул.

Белдерү

ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ ПО СОГЛАСОВАНИЮ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦЫ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА

Кадастровым инженером Елисеевой Анной Андреевной (почтовый адрес: 420029, Российская Федерация, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Пионерская, д. 17, офис 218, адрес электронной почты: 2582972@mail.ru, контактный телефон: +79600482972, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляющих кадастровую деятельность 39328, СНИЛС: 136-282-280-56, является членом СРО АКИ «Поволжье») выполняются кадастровые работы в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:24:255801:23, Республика Татарстан, Лаишевский муниципальный район, Орловское сельское поселение, садоводческое некоммерческое товарищество «Сосновый», участок 23. Номер кадастрового квартала: 16:24:255801. Кадастровые номера смежных земельных участков: 16:24:255801:22, 16:24:255801:599, 16:24:255801:259.

Заказчиком кадастровых работ является Яруллина Людмила Дмитриевна. Собрание по поводу согласования местоположения границы состоится по адресу: Российская Федерация, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Пионерская, д. 17, офис 218 20 апреля 2023 г. в 9 часов 30 минут. С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Пионерская, д. 17, офис 218. Требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 15 марта 2023 г. по 20 апреля 2023 г., обоснованные возражения о местоположении границ земельных участков после ознакомления с проектом межевого плана принимаются с 15 марта 2023 г. по 20 апреля 2023 г. по адресу: 420029, Российская Федерация, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Пионерская, д. 17, офис 218. Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границы земельного участка: 16:24:255801:599.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 года N 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

Үз өемдә – үз телем

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстанда үз өен тапкан төрле милләтләрнең яшәеше, милли гореф-гадәтләре белән таныштыра, бер гаилә мисалында «Туган телне ничек сакларга?» дигән сорауга җавап эзли.

УДМУРТ

ЫШАНЫЧ

Балтач районы

Сала Көшкәт авылында яшәүче Камаевлар, туган телне саклауда гаилә музыка, гореф-гадәт һәм милли бәйрәмнәр – барысы да мөһим роль уйный, дип саный. Бу җәһәттән бүгенгә аларның күңелләре тыныч, ә киләчәкләре ышанычлымы?

Тел бишеге – гаилә

Камаевларның ишле гаиләсе безне ике катлы зур йорт бусагасыннан ук икмәк, тоз һәм җырлар белән каршы алды. Төп йортта өч буын – гаилә башлыгы Виктор һәм Алевтина, уллары Михаил белән киленнәре Ирина, оныклары Антон белән Андрей яши. Берничә ел элек гаилә башлыгының әтисе мәрхүм булганчы, бер түбә астында дүрт буын гомер иткән. Камаевларның кызлары Лилия Чирикова да гаиләсе белән шушы авылда гына яши. Безнең белән очрашуга ул ике кызы Кира белән Лираны да алып килгән иде.

– Никтер хәзер яшьләр өлкән буын белән бер түбә астында яшәү яклы түгел, – ди Виктор Камаев. – Ә без моның бары тик яхшы якларын гына күрәбез. Беренчедән, бер-беребезгә ярдәмләшәбез, туганлык җепләре ныгый. Әниләре эштә булганда, балаларга һәрвакыт күз-колак булучы бар. Моннан тыш, өйдәге барлык зур эшләрне бергәләп башкарабыз. Икенчедән, оныклар телне белеп үсә, чөнки өйдә без бары тик туган телебездә генә аралашабыз. Монысы безнең өчен бигрәк тә кадерле.

Сүз йомгагыбыз тел кадеренә барып тоташкач, киленнәре Ирина да үз фикерен әйтте.

– Мин моны үземнән дә чыгып әйтә алам. Мин Мари Илендә туып-үстем. Әлеге гаиләгә килен булып төшкәнче, удмуртча бөтенләй аралашмый идем, чөнки безнең якларда тел сакланмаган диярлек. Телне мин шушы гаиләдә чарладым, һәм хәзер бары тик туган телемдә генә аралашам, – диде ул.

Бәлки шуңа күрәдер, гаилә башлыгы Виктор Камаевның бу уңайдан күңеле тыныч.

– Мин нәселебезнең телне буыннан-буынга тапшырасына өметләнәм, ышанам, – ди өлкән буын вәкиле Виктор. – Барысы да гаиләдән килә. Әгәр өйдә үзара удмуртча сөйләшү юк икән, тел югалачак. Шәһәргә киткән яшьләр төп тел буларак рус телен сайлый икән, борчылырлык урын бар, чөнки мондый гаиләдә үскән балалар телне акрынлап оныта. Миңа калса, тел авылларда күбрәк һәм ныграк саклана. Сала Көшкәттә удмурт булып сакланыр өчен мөмкинлекләр күп әле. Чөнки 200 кешеле авылда барыбыз да удмуртча гына аралаша.

Телне гаиләдә генә саклап калып була, дигән фикерне урта буын вәкиле Михаил да куәтләде.

– Сабый баланың теле туган телендә ачыла бит. Миңа улларым үзебезчә, яратып, «атай» дип эндәшә. Хәзер балалар бакчасында ук күп сабыйлар руслаша башлый. Мәктәптә бу күренеш дәвам итә. Димәк, телне саклауның төп учагы – гаилә, – диде ул.

Виктор Камаевның педагоглык стажы 38 елга тулган. Ул озак еллар удмурт телен һәм әдәбиятын укыткан. Әле хәзерге көнгә кадәр мәктәптә эшли ул, тормыш иминлеге нигезләре, музыка һәм физкультура дәресләрен алып бара. Кызлары Лилия дә әтисе юлыннан киткән, башлангыч сыйныфларда укыта.

– Безнең мәктәптә, әйләнә-тирәдәге авылларда тел югалу куркынычы юк, – дип, үз фикерен җиткерде Лилия Чирикова. – Ә менә бездән бераз ераграк булган удмурт авылларында күбрәк русча аралашалар. Безнең мәктәпкә балалар алты авылдан килеп укый. Алар барысы да удмуртча сөйләшә әле, чөнки гаиләдә эти-әниләр балалары белән туган телдә аралаша. Без үзебезгә бары тик үзебез генә ярдәм итә алабыз, читтән ярдәм көтәргә кирәкми. Телне саклау – гаиләдә, эти-әнидә. Кешеләр, адашып, ничек кенә туган телләреннән йөз чөерергә тырышса да, туган телдән качып булмый. Без удмурт булып туганбыз һәм удмурт булып яшәргә тиеш. Ничек кенә булса да, аңыбыз башта туган телдә фикерләячәк, аннан соң гына башка телдә булырга мөмкин.

Өлкәннәр булмаганда да балаларның үзара бары тик туган телләрендә генә аралашуына игътибар иттек. Шулай да кызларның әниләре Лилия әйтүенчә, балалар русчага да еш күчә.

– Малайлар үзара удмуртча аралаша әле. Ә менә минем кызлар Лира белән Кира күп вакытларын телефонда утыргач, сөйләмнәрендә рус сүзләре күп, – диде ул. – Ирем белән ничек тә моны чикләргә тырышабыз. «Без русча аңламыйбыз, әйдәгез, удмуртча сөйләшик әле», – дибез. Әтиләре белән бары тик удмуртча гына аралашам. Рус теле дә кирәк, әлбәттә, ләкин туган телләрен онытмасын иде балалар.

Җыр-моң

Моның өчен нәрсә эшләргә соң? Әлеге сорауны Виктор Камаев үз-үзенә берничә ел элек биргән һәм анык кына фикергә килгән. Аның әйтүенчә, телгә булган кызыксыну, ихтирам уятуның бер ысулы – оныкларны җырга-моңга тарту.

Гаилә башлыгы гармун уйный, җырлый. Балалар, оныкларга да әтиләренең һәм бабайларының сәләте күчкән. Дүрт онык та җырлый, шигырьләр сөйли, бәйрәм чараларын алып баралар, бик күп республика конкурсларында җиңү яулаганнар.

– Әти-әнием матур итеп җырлый иде. Улым Михаил да моңга һәвәс, минем кебек гармун уйный. Авылда гармун уйнаучылар башка юк диярлек, шуңа күрә егетләр армиягә киткәндә һәрвакыт аны чакыралар. Бер төркем ир-атлар, җырлап, биеп, урам әйләнеп уза.

Хәер, бу гаиләдә җыр, биюнең еш кунак булуына үзебез дә инандык. Бер сүз әйтү җитә, балалар шундук өлкәннәргә кушылып җырлап та җибәрә, тыпыр-тыпыр биеп тә китә. Оныгы Антон гаилә, туган тел турында җырлаганда, бабасы хәтта күз яшьләрен тыя алмады.

– Безнең өйдә җыр-моң тынып торганы юк, – ди Виктор Камаев, ихластан елмаеп. – Кунаклар килсә, һичшиксез музыка яңгырап тора. Җырларның эчтәлекләре дә махсус сайлап алына, заманча җырлар да җырлана, әлбәттә. Йортта үзебез генә булганда да кулыма гармун алам. Аннан соң мин бит мәктәптә фольклор түгәрәге алып барам, ансамбльне җитәклим. Укучыларга удмурт җырларын, биюләрен, йолаларын, гореф-гадәтләрен, такмазаларны өйрәтәбез.

Кадерле ядкарь

Камаевлар гаиләсе буыннан-буынга тапшырыла торган бүләкләрне кадерле ядкарь итеп саклый. Әйтик, киленнәре Ирина кулына таккан беләзеге (поскес) әбисенең истәлеге буларак кадерле. Шулай ук гаиләдәге иң өлкән хатын-кыз Алевтина ханымда әлегә кадәр ерак әбисенең күлмәге саклана. Күлмәк өстеннән киелә торган камзул, алъяпкычлы милли кием гаиләдәге һәр хатын-кызда бар. Билгеле, соңгы елларда алар аны бик сирәк, аерым бер очракларда гына кияләр. Мәсәлән, кияү ягыннан булган туташлар, ханымнар кыз сорарга барганда милли киемнәрен кия.

Тагын бер милли аксессуар – күкрәкчә (камали) шулай ук гаиләдәге һәр хатын-кызда бар. Алевтина ханым әйтүенчә, ул йорттан чыгарга тиеш булмаган. Ягъни аны кызга түгел, ә киленгә тапшырганнар. Камали өйдән чыкса, начарга юраганнар.

– Көмеш тәңкәләр белән бизәлгән камали хәлле гаиләләрдә генә булган. Кызганыч, безгә дә ул әби-бабайларыбыз аша күчмәде, технология дәресендә үзебез ясаган идек. Хәзер технология дәресе юк. Шулай булгач, киләчәктә камали турында сөйләүчеләребез, аны ясарга өйрәтүчеләрбезнең дә булмавы бар. Ләкин аны барыбер сакларга, өйдә булдырырга тырышалар, – дип аңлатып китте Лилия.

Көмеш тәңкәләр белән бизәлгән камали өч өлештән тора. Беренчесе – башка кия торганы такъя дип атала. Аның нәкъ уртасына зур тәңкә куелырга тиеш икән. Кыз балалар шул килеш кенә кисә, кияүдәге ханымнар такъя өстеннән яулык яба. Борынгы тәңкәләр белән эшләнгән һәм муен тирәсенә тагыла торган өлеше чыртыкыч дип атала. Аннан соңгысын гадыгы һәм иң озын өлешен камали дип атаганнар.

Гадыгыга төрле төстәге тасмалар беркетелсә, алъяпкыч һәм камалиның сул ягына матурлык өчен яулык бәйләп куела.

– Туй көнне кияүнең туганнары кәләш алырга барганда күлмәк өстеннән камалины да тага. Элек яшьләр өйләнешкәндә тулы бер йола башкарыла һәм туйны 4 көн бәйрәм итәләр иде. Моңа бөтен авыл халкы кушыла иде. Яшьләр һәр йортта кадерле кунак булды. Хәзер бары тик кәләш йортында гына җырлар җырлыйлар, такмаклар әйтәләр дә, туйның калган өлеше заманча – кафе яки ресторанда уздырыла, – ди Алевтина ханым.

Шунысы да бар: бу авылда барлык киленнәрне дә урлап алып кайталар. Камаевлар да киленнәре Иринаны күрше авылга кунакка килгән җиреннән алып кайтканнар.

– Михаил белән ике ел очрашып йөрдек. Урлау гадәте барлыгын белсәм дә, көнен алдан әйтеп тормады. Өйдәгеләрне кисәткән дә, кичен мине машинага этеп-төртеп утыртып, урлап алып та кайтты. Гадәттә яшь егетләр кызның өенә барып, шәраб һәм аның янына кияүнең адресларын язып калдыра. Иртән алар кызлары килен булып төшкән йортка кунакка килергә тиеш була. Кире алып кайтып киткән очраклар да булган. Тик бу кыз балага бәхетсезлек китерә, ягъни бәхете әлеге йортта кала, дип саналган, – диде Ирина.

Гореф-гадәт

Телне саклауда гореф-гадәт, милли ризыклар, йолаларның роле зур, дип саный Камаевлар. Удмуртлар Троица, Пасха, Кичтон (әти-әниләр шимбәсе) бәйрәмнәрен билгеләп уза. Тик Виктор Камаев фикеренчә, бәйрәмнәрнең асылы, мәгънәсе сакланса да, эчтәлеге үзгәреш кичерә:

– Элек Кичтон бәйрәме зурлап уздырыла, туганнар, авылдашлар йорттан-йортка йөреп бәйрәм итә иде. Хәзер һәркем үз туганнары белән генә уздырып җибәрә. Хәрби хезмәткә китүче егетне бөтен авыл халкы белән озату йоласы да безнең авылда гына сакланды.

Шулай ук тәңречелек, изге урыннарның да көче акрынлап кими, ди ул. Изге җир буларак билгеле урыннар сакланса да, корбан чалу, табыну, дога кылу йолалары башкарылмый икән.

– Традицияләр тулысынча югалмый, ләкин аларның кайбер өлешләре онытыла, үтәлми. Мәсәлән, әбиләр заманында тәңречелек көчле иде. Ул вакытта кешеләр «луд» дип Ходайга корбан китерә иде. Безнең авылда ике – Пөша луд, Чола луд булган. Корбан китерә, дога кылына торган урыннар изге булып санала, аннан бернәрсә алырга да, тияргә дә ярамый иде. Андый изге урын безнең бакчада да бар. Йоласын башкармасак та, без дә, балалар да бу җиргә берни дә утыртмыйбыз, чәчмибез. Бакча уртасында шулай утраучык булып тора. Бу хакта оныкларга да аңлатып сөйләдек. Алар әлеге урыннан таш та, җир дә алырга ярамаганлыгын белеп үсә, – ди гаилә башлыгы.

Мәктәп

Сала Көшкәт авылы балалары 3 чакрым ераклыктагы Урта Көшкәт авылы мәктәбенә барып укый. Биредә ун авылдан 116 бала: удмуртлар, татарлар һәм руслар белем ала. Тагын 30 бала бакчага йөри.

Мәктәп директоры Константин Грахов әйтүенчә, нигездә рус телендә белем бирәләр. Удмурт телен туган тел буларак укыйлар.

– Мәктәптә укучылар үзара башлыча удмуртча аралаша. Татарлар һәм руслар булган классларда аралашу теле – русча, – диде ул. – Шулай да соңгы елларда балаларның руслашуын күрәм, сизәм. Миңа калса, бу, беренче чиратта, гаиләдән килә. Икенчедән, балалар бакчасында да проблема бар. Моны мин үз улым мисалында да әйтә алам. Ул Чепья балалар бакчасына йөри. Теле бөтенләй русчага күчеп бетте. Ачык кына сәбәбен дә әйтә алмыйм. Анда бит күбрәк татар балалары йөри. Ник шулай килеп чыга ул? Белмим.

Монда телефон, гаджетларның да йогынтысы зур, дип саный Константин Грахов. Ул телефондагы һәр кушымтаны, уеннарны төрле телләрдә эшләсеннәр, һәм һәр бала үз туган телендә уеннар уйнасын иде, дигән фикерен җиткерде.

– Сәләтле яшьләребез, оешмаларыбыз күп. Алар моны эшли дә алырлар иде, бәлки, – ди ул.

Удмурт теле һәм әдәбияты укытучысы Римма Петрова сөйләвенчә, балаларга атнасына өч мәртәбә туган тел дәресе укыталар. Икесе – удмурт теле, берсе – әдәбияты.

– Укучыларның барысы да туган тел буларак удмурт телен сайлады. Бу уңайдан бездә проблемалар юк. Ул 2 нче сыйныфтан алып 11 нчегә кадәр укытыла. Укучылар үзара күбрәк удмуртча сөйләшә, ләкин соңгы вакытта балалар бакчасында руслашу күзәтелә. Башлангыч сыйныфларда да укучылар шул гадәт буенча русча аралаша. Кызганыч, соңгы берничә елда бу бигрәк тә нык сизелә. Шуңа күрә бөтен ышаныч – гаиләдә. Тик балалары белән русча гына аралашучы гаиләләр саны да арта. Гаиләдә туган телендә аралашкан бала мәктәптә дә удмуртча сөйләшә һәм мәктәп программасын да күпкә җиңелрәк үзләштерә, – диде ул.

Римма Петрова дәреслекләр проблемасын да күтәрде.

– Алтынчы сыйныфтан башлап удмурт теле буенча яңа дәреслекләр юк. Әдәбият дәреслекләре 10–11 нче сыйныфларда гына юк. Шуңа күрә иске китаплардан укытырга туры килә. Яңа дәреслекләр була-була дип әйтәләр, тик яңа стандартлар кертелү сәбәпле, алар таләпләргә җавап бирмәячәк, – диде укытучы.

Аның әйтүенчә, балалар мәктәп китапханәсендәге удмуртча китапларны, газеталарны да сирәк укый.

Борчыган тагын бер мәсьәлә бар. Баксаң, Урта, Кече һәм Сала Көшкәт авылларында яшәүчеләр шошмин диалектында аралаша икән.

– Безнең сөйләмдә алынма сүзләр күп. Ул әдәби телдән шактый аерыла, – ди Лилия. – Шунлыктан безнең балаларга мәктәптә тел өйрәнү авыр бирелә. Дәреслекләрдә бер үк сүз бөтенләй башкача языла. Өстәвенә заманча удмурт теленә дә яңа сүзләр өстәлеп тора. Балаларга гына түгел, хәтта әти-әниләргә дә кыенга туры килә. Балалар белән бергә телне кабаттан без дә өйрәнәбез.

ЧӦЖЫ ТАБАНЯНЬ СИЁН

Удмуртлар муллык ярата. Камаевлар да, барысы да үзебезнеке булсын дип, сыер да, бозау да, дуңгыз да асрый. Җәен ишегалды тутырып кош-кортын да тәрбияли. Шуңа күрә аларда терлекләргә бәйле йолалар бар. Әйтик, бозау тугач, алар сыерның угыз сөтеннән коймак (табани) пешереп, чӧжы табанянь (эремчеккә охшаган ризык) ясап, кунакларны табын янына җыя. Әйтергә кирәк, бу йола Камаевлар гаиләсендә дә, авылда да бүгенгәчә сакланган. Чӧжы табанянь сиён бәйрәменә җыелган кунаклар табынга утыргач, хуҗабикә аларның маңгайларына калак белән сугып чыга. Бу шаяру катыш гадәт «безнең бозау шулай сөзә» дигәнне аңлата икән. Шуннан соң йорт хуҗалары, кунаклар, җырлар җырлап, биеп, кәеф-сафа корып утыра.



ВИДЕО

Сәхифәне Зөһрә САДЫЙКОВА әзерләде.
Фото – Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5332 данә
Гомуми тираж – 15281 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 236

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+